

Ноябрь аенда моселманнар Мохәм-мәтнен туган коненә багышлап Мәvлет бәйрәмен билгеләп vтәләр. Бу конне туганнар, дуслар, авылдашлар, милләттәшләр белән жыелып вәгазьләр тынлап, догалар укып, салаватлар әйтеп, теләкләр теләнә.
Дини оешмалар белән беррәттән, бу бәйрәмне хәзер Россия тобәкләрендәге, чит илләрдәге татар ижтимагый оешмалары, мәдәни vзәкләре дә билгеләп vтә. Шулай, 24нче ноябрьдә Саранск-тагы «Ускудар» мәчетендә кvп иттереп моселманнар Мәvлет бәйрәменә жыелдылар.

Регионыбыз Жомһvрияте Диния Назәрәте (Региональное ДУМ РМ) житәкчесе Зәки Абдулкәрим улы Айзатуллин дини бәйрәмне алып барды. Чарага чакырылган кунаклар арасында Самара олкәсе Региональ Жомһvрияте Диния Назәрәте житәкчесе Талип Вагиз улы Яруллин мофти, Пенза олкәсе баш имамы Ислям Ибрагим улы Давыдов, дини эшләр буенча Дагестан мофтие ярдәмчесе Магомед Ибраһимхәлил улы Абдурахманов, дини эшләр буенча Дагестаннын милли сәясәт Министрлыгы вәкиле Азхаб Мамай улы Мурзаев, Россия регионнарында һәм чит илләрдә жирле халык белән хезмәттәшлек итv буенча Жәмгыяви Шура әгъзасы Шәмил Магомедбәсир улы Алиев, Ульян олкәсе Региональ Жомһvрияте Диния Назәрәте вәкилләре, жирле дини оешмалар имамнары һәм әгъзалары, Ялга балалар ой-мәктәбендә тәрбияләнvчеләр, жәмгыять эшлеклеләре һәм башкалар булдылар. Бар галәмгә Аллаһнын рәхмәте булып килгән Мохәммәд Пәйгамбәрнен кvркәм Мәvлет кичәсе Коръән аятьләрен укудан башлана. Шулай, жаваплы вазыйфа Пенза олкәсе Исса жирлеге мәчете имамы Акмалдин хазрәт Самиевка йокләнгән иде. Бик матур башкарудан сон, Бәйрәм белән котлап дин кардәшләребезгә изге теләкләр, илебезгә иминлек, бәрәкәт Зәки хазрәт Айзатуллин теләде. Ислам дине олкәсендә, жәмгыятебезнен рухи vсешенә зур олеш керткән, илебездә тынычлык һәм дуслык орлыгы оләшкән Ромодан районы Белозерье авылындагы «Үзәк» дигән дини оешма житәкчесе Мянсур Сайяф улы Базеевка, Ләмберә районы Инят авылы имам-хатыйбы Галяв Сайяф улы Азисовка Рәхмәт хатлары мофти тапшырды. Аннары кунаклар, хормәт йозеннән, дини вәгазь белән бергә, бер-берсенә бvләкләр тапшырдылар. Олыларнын чыгышы арасында балалар Пәйгамбәребезгә багышлап ятлап килгән шигырьләрен сойләделәр. Рәхмәт йозеннән аларга баллы бvләкләр белән «Аятел-Корси» догасы панносы тапшырылды.
Рабигыль-әvвәл – Ислам тарихында ин соекле айларнын берсе, чонки бу ай бар Галәмгә рәхмәт буларак (григориан ел исәбе буенча 571нче елда) Пәйгамбәр килvе белән истәлекле. Бәйрәмдә Пәйгамбәребезгә багышлап нәшедләр, салаватлар һәм касыйдалар әйттеләр.

